ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел/факс 5-75-19
19 ноябрь 2020ел

СОВЕТ ТАТАРСКО-
ЯМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел/факс 5-75-19

КАРАР | РЕШЕНИЕ

21.11.2022г. | № 13

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татар Ямалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Татар Ямалы авыл җирлеге җыены карар бирә:

1. 2022 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, Бөек Ватан сугышы ветераннарынан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын; Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән кала, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Күмү урыннарын карап тоту;

- Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

* юлларны формалаштыру һәм тигезләү, ком һәм таш салу , грейдер белән тигезләү, кардан чистарту;

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү һәм су чыганакларын документаль рәсмиләштерү;

- Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру;

2. Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге гражданнарының халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

Татар Ямалы авыл җирлеге советы рәисе [подпись] Д.Ф.Валиев